КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 июль г.Казань № 586

«Казан» Халыкара ат-спорт комплексы территориясендә 2023 елда яңа ел чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнар өчен түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда башка бюджетара трансферт бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Декабрьга теркәлгән «Казан» Халыкара ат-спорт комплексы территориясендә 2023 елда яңа ел чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнар өчен түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда башка бюджетара трансферт бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 20 июль, 586 нчы карары белән расланды

«Казан» Халыкара ат-спорт комплексы территориясендә 2023 елда яңа ел чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнар өчен түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда башка бюджетара трансферт бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Казан» Халыкара ат-спорт комплексы территориясендә 2023 елда яңа ел чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнар өчен түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда башка бюджетара трансферт бирү механизмын билгели (алга таба - тиешенчә муниципаль берәмлек, башка бюджетара трансферт).

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансферт  тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 пунктында каралган максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондыннан бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты белән билгеләнә.

5. Башка бюджетара трансферт бирү һәм аны тоту шартлары түбәндәгеләр:

«Казан» Халыкара ат-спорт комплексы территориясендә 2023 елда яңа ел чараларын үткәрү өлешендә чыгым йөкләмәләрен билгели торган муниципаль хокукый акт булу;

әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә Министрлык һәм  муниципаль берәмлекнең җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы (алга таба - вәкаләтле орган) арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү;

6. Башка бюджетара трансферт алу өчен вәкаләтле орган Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

«Казан» Халыкара ат-спорт комплексы территориясендә 2023 елда яңа ел чараларын үткәрү өлешендә чыгым йөкләмәләрен билгели торган муниципаль хокукый актның таныкланган күчермәсе;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансферт бирү турында заявка.

7. Министрлык әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән алып 30 көн эчендә аларны карый һәм башка бюджетара трансферт бирү турында йә башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта вәкаләтле органга карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә хәбәр итә.

8. Башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

9. Башка бюджетара трансферт башка бюджетара трансферт бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә Министрлык һәм вәкаләтле орган арасында төзелә торган килешү буенча бирелә.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансферт күләме, аның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертны күчерү тәртибе;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны тапшыру формасы һәм сроклары;

муниципаль берәмлек башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек тарафыннан килешү белән каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

11. Башка бюджетара трансферт килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

12. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын нәтиҗәле файдалану максатларында башка бюджетара трансферттан файдалану һәм башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешү 2024 елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

13. Вәкаләтле орган, 2024 елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап тапшыра.

14. Башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе булып «Казан» Халыкара ат-спорт комплексы территориясендә 2023 елда яңа ел чараларын үткәрүгә бәйле товарлар, эшләр сатып алуга, хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр буенча контрагентлар (башкаручылар) алдында кредиторлык бурычы булмау тора.

15. Вәкаләтле орган Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең дөрес булмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

16. Башка бюджетара трансфертны максатчан файдаланмаган һәм (яисә) муниципаль берәмлек аны аңа бирү шартларын бозган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган бюджет мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

17. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары муниципаль берәмлекнең башка бюджетара трансферт бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерә.

18. Башка бюджетара трансферттан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

19. 2025 елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертның калган өлеше 2025 елның беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

20. Башка бюджетара трансферттан максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

---